ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево, 422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы, 422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

07.11 с. Татарское Бурнашево

Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына 22.11.2013 ел № 909 (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 нче елның 22 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Татар Борнашы авыл җирлегенең Каинки авылы гражданнарына үзара салым кертү буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

(Татар Борнашы авылында юлларны ремонтлау өчен асфальт гранула сатып алып, билгеләнгән пунктка илтеп җиткерү).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Татар Борнашы авылы, Совет урамы, 62 йорт адресы буенча 11.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Җыенны оештыручы итеп Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин